РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
НИЖНЕНАРАТБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН НАРАТБАШ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

« 30 » декабрь 2020 № 9-2

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 14 ноябрндәге 42-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Муниципаль берәмлекләр территорияләрен карап тотуга санитар-эпидемиологик таләпләр һәм санитар-эпидемиологик кагыйдәләрне раслау турында» Россия Федерациясенең 2019 елның 5 декабрендәге 20 номерлы Баш дәүләт санитар табибы карары, Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеге Советының 2017 елның 14 ноябрендәге 42-2 номерлы карары белән «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Түбән Наратбаш авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренә (14.07.2018 ел, № 53-3, 10.09.2009 ел, № 74-1, 05.08.2020 ел, № 95-1 карарлары редакциясендә) (алга таба - Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

Кагыйдәләрнең 104 пунктына түбәндәге эчтәлекле 104.5 пунктча өстәргә:

«104.5 Җирләү урыны территориясендә агач һәм куаклар утырту рөхсәт ителми.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча басылып чыккан көненнән закон көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
Түбән Наратбаш авыл җирлеге башлыгы Д.Х. Абдрахманов